ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.03.2020 Казан шәһәре № 9-3/соц-2020

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Дәүләт техник исәбе һәм капиталь төзелеш объектларын техник инвентарьлаштыру өлкәсендәге норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы торак фондын техник инвентарьлаштыруга ставкалар билгеләү турында» 2018 елның 18 декабрендәге 8-2/соц карарына үзгәрешләр кертү хакында

Норматив хокукый актларны актуальләштерү максатларында Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Дәүләт техник исәбе һәм капиталь төзелеш объектларын техник инвентарьлаштыру өлкәсендәге норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы торак фондын техник инвентарьлаштыруга ставкалар билгеләү турында» 2018 елның 18 декабрендәге 8-2/соц карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «2017-2019 елларга Татарстан Республикасы торак-коммуналь хуҗалыгы оешмалары буенча Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы, «Татарстан Республикасы коммуналь предприятиеләре берлеге» эш бирүчеләрнең төбәк тармак берләшмәсе һәм Татарстан Республикасы тереклек тәэмин итү эшчеләре һөнәри берлегенең Республика комитеты арасында төзелгән тармак килешүе,» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Техник инвентарьлаштыру бюросы» акционерлык җәмгыяте өчен дәүләт техник исәбе һәм капиталь төзелеш объектларын техник инвентарьлаштыру өлкәсендәге норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы торак фондын техник

инвентарьлаштыруга әлеге карар кушымтасына ярашлы рәвештә ставкалар билгеләргә.».

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром